КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 ноябрь г.Казань № 960

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күргәзмә чараларында Татарстан Республикасы экспозицияләрен оештыруга, форумнарда, күргәзмәләрдә, конгрессларда, конференцияләрдә, коллегияләрдә, съездларда, семинарларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында катнашуга, аларны оештыруга һәм үткәрүгә, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре өчен кадрлар әзерләүгә һәм үстерүгә бәйле булган чараларны үткәрүгә, шулай ук һөнәри белем бирү юнәлешендәге бәйрәм чараларын оештыруга бәйле булган чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 15 август, 820 нче карарына үзгәрешләр кертү хакыда

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күргәзмә чараларында Татарстан Республикасы экспозицияләрен оештыруга, форумнарда, күргәзмәләрдә, конгрессларда, конференцияләрдә, коллегияләрдә, съездларда, семинарларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында катнашуга, аларны оешты-руга һәм үткәрүгә, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре өчен кадрлар әзерләүгә һәм үстерүгә бәйле булган чараларны үткәрүгә, шулай ук һөнәри белем бирү юнәлешендәге бәйрәм чараларын оештыруга бәйле булган чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 15 август, 820 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 19 декабрь, 1369 нчы, 2023 ел, 22 апрель, 514 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күргәзмә чараларында Татарстан Республикасы экспозицияләрен оештыруга, форумнарда, күргәзмәләрдә, конгрессларда, конференцияләрдә, коллегияләрдә, съездларда, семинарларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында катнашуга, аларны оешты-руга һәм үткәрүгә, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре өчен кадрлар әзерләүгә һәм үстерүгә бәйле булган чараларны үткәрүгә, шулай ук һөнәри белем бирү юнәлешендәге бәйрәм чараларын оештыруга бәйле булган чыгымнарны каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) һәм индивидуаль эшкуарларга  Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм сайлап алуны уздыруга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары нигезендә  Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Күргәзмә чараларында Татарстан Республикасы экспозицияләрен оештыруга, форумнарда, күргәзмәләрдә, конгрессларда, конференцияләрдә, коллегияләрдә, съездларда, семинарларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында катнашуга, аларны оешты-руга һәм үткәрүгә, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре өчен кадрлар әзерләүгә һәм үстерүгә бәйле булган чараларны үткәрүгә, шулай ук һөнәри белем бирү юнәлешендәге бәйрәм чараларын оештыруга бәйле булган чыгымнарны каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) һәм индивидуаль эшкуарларга  Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.»;

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

Әлеге карар белән расланган Күргәзмә чараларында Татарстан Республикасы экспозицияләрен оештыруга, форумнарда, күргәзмәләрдә, конгрессларда, конференцияләрдә, коллегияләрдә, съездларда, семинарларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында катнашуга, аларны оештыруга һәм үткәрүгә, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре өчен кадрлар әзерләүгә һәм үстерүгә бәйле булган чараларны үткәрүгә, шулай ук һөнәри белем бирү юнәлешендәге бәйрәм чараларын оештыруга бәйле булган чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән).

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 15 август, 820 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 5 ноябрь, 960 нчы
карары редакциясендә)

Күргәзмә чараларында Татарстан Республикасы экспозицияләрен оештыруга, форумнарда, күргәзмәләрдә, конгрессларда, конференцияләрдә, коллегияләрдә, съездларда, семинарларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында катнашуга, аларны оешты-руга һәм үткәрүгә, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре өчен кадрлар әзерләүгә һәм үстерүгә бәйле булган чараларны үткәрүгә, шулай ук һөнәри белем бирү юнәлешендәге бәйрәм чараларын оештыруга бәйле булган чыгымнарны каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләрне раслау һәм күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрү турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән һәм күргәзмә чараларында Татарстан Республикасы экспозицияләрен оештыруга, форумнарда, күргәзмәләрдә, конгрессларда, конференцияләрдә, коллегияләрдә, съездларда, семинарларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында катнашуга, аларны оештыруга һәм үткәрүгә, сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре өчен кадрлар әзерләүгә һәм үстерүгә бәйле булган чараларны үткәрүгә, шулай ук һөнәри белем бирү юнәлешендәге бәйрәм чараларын оештыруга бәйле булган чыгымнарны каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидия, чара).

1.2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бюджет чараларын баш бүлүче буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба - вәкаләтле орган) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга гамәлгә ашырыла.

1.3. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

тәкъдим (заявка) – сайлап алуда катнашу өчен әлеге Тәртип таләпләре нигезендә рәсмиләштерелеп тапшырыла торган документлар;

килешү - вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелә торган субсидияне Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү турында килешү.

Әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

1.4. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

1.5. Вәкаләтле органның сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге документларны электрон рәвештә «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба - «Электрон бюджет» системасы) файдаланып гамәлгә ашырыла.

1.6. «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

## II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидия сайлап алуда катнашучыларга чараларны оештыруга һәм уздыруга бәйле расланган чыгымнарны каплау максатларында бирелә.

2.2. Субсидия алучыны (алучыларны) сайлап алу, сайлап алуда катнашучының сайлап алу критерийларына һәм тәкъдимнәр (заявкалар) керү чиратына туры килүеннән чыгып, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәр (заявкалар) нигезендә үткәрелә.

2.3. Тәкъдимне (заявканы) карау һәм килешү төзү датасына торышы буенча сайлауда катнашучыга туры килергә тиешле таләпләр:

сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган)

акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

сайлап алуда катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормау;

сайлап алуда катнашучы БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

сайлап алуда катнашучы бу Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаска тиеш.

сайлап алуда катнашучы «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тиешле очраклардан тыш);

юридик зат булган сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау, ә индивидуаль эшмәкәр булган сайлап алуда катнашучы үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридки зат булган сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында, индивидуаль эшкуар турында мәгълүматлар булмау;

2.4. Сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү автомат рәвештә «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба - дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, гамәлгә ашырыла.

«Электрон бюджет» системасында автомат тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлауда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәү турында тамгаларны электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Вәкаләтле органның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта Вәкаләтле орган сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел, сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Вәкаләтле органга тапшырырга әзер булган очрактан тыш.

2.5. Кайтару өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре булып субсидия алучы тарафыннан түбәндәгеләргә тотылган чыгымнар тора:

корылмаларны, вакытлыча төзелгән корылмаларны да кертеп, бүлмәләрне, мәйданчыкларны, транспортны арендалау, техник хезмәт күрсәтү өчен түләү;

күргәзмә экспозициясен төзү, чаралар үткәрү өчен бүлмәләрне декорация-техник бизәү, җиһазларны монтажлау/демонтажлауны кертеп;

чараларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле техник чараларны һәм ярдәмче җиһазларны арендалау, сатып алу;

чараларны гамәлгә ашыру өчен канцелярия товарлары, полиграфия продукциясе һәм башка чыгым материаллары әзерләү һәм сатып алу;

дәүләт һәм бүләкләү атрибутикасын, символикасын әзерләү һәм сатып алу;

гражданлык-хокукый шартнамәләр нигезендә җәлеп ителгән белгечләр хезмәтләре өчен түләү, шул исәптән чараларны оештыру һәм уздыру өчен автор заказы шартнамәләре нигезендә;

биналарны, мәйданчыкларны, корылмаларны, шул исәптән, чараларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле вакытлыча, төрле конструкцияләрне дә кертеп, монтаж һәм демонтажны да кертеп рәсмиләштерү;

чараның реклама кампаниясен үткәрү, басма мәгълүмати продукция җитештерү һәм тарату, шул исәптән аны монтажлау һәм демонтаж, фото- һәм видеога төшерү, медиаконтент ясау, видеороликлар һәм видеофильмнар ротацияләү;

вәкиллекле (сувенир), чәчәкле продукция һәм призлар әзерләү һәм сатып алу;

мәдәни программаны оештыру һәм чараларга экскурсия хезмәте күрсәтү;

чарада тукλануны оештыру;

программа һәм мәгълүмати тәэмин итү, IT-технологияләр;

ашыгыч ярдәм күрсәтү хезмәтләре өчен медицина ярдәме күрсәтү һәм түләү;

элемтә хезмәтләре, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, курьер аша илтеп җиткерү һәм почта чыгымнарыөчен түләү;

чараларда катнашучыларны аккредитацияләү, шул исәптән теркәү кертемнәрен һәм җыемнарын түләү;

чарада катнашучыларны транспорт белән тәэмин итү (трансфер), килүче һәм кимеүче чараларга махсус хезмәт күрсәтү;

субсидия алучы персоналның яшәве, аларга транспорт хезмәте күрсәтү;

чараларны уздыру өчен синхрон күчерү өчен җиһазлар, тавыш, яктылык һәм мультимедиа җиһазлары, шулай ук башка инвентарь арендалау һәм тәрҗемә хезмәтләре өчен түләү;

чаралар үткәрүгә турыдан-туры бәйле оештыру кертемнәре.

2.6. Бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + ... + З_n,$$

монда $З_1$, $З_2$, ..., $З_n$ – бу Тәртипнең 2.5 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган оештыручы-җитештерүчеләрнең бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар суммасы.

2.7. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

субсидияләр бирү елының 31 декабренә кадәр чараларда катнашкан физик затлар һәм эшкуарлык субъектлары саны (кимендә 100 кеше);

чарада катнашкан экспертлар саны (иҗтимагый эшлекле берләшмәләр, федераль институтлар вәкилләре, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары вәкилләре, кредит оешмалары вәкилләре) - субсидия бирелгән елның 31 декабрьгә кадәр кимендә 10 кеше;

чара турында массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгару саны - субсидия бирелгән елның 31 декабренә кадәр булган чара турында кимендә бер басма.

## III. Сайлап алуны үткәрү тәртибе

3.1. Вәкаләтле орган тәкъдимнәр (заявкалар) кабул итү датасына кадәр бер көннән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза салынганнан соң һәм субсидия турындагы бердәм мәгълүмат порталында бастырып чыгарылганнан соң, сайлап алу үткәрелү турында игълан урнаштыра.

Сайлап алуны уздыру турында игълан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаша, вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән зат) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда бастырыла.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

тәкъдинәрне (заявкаларны) бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану даталары. Заявкалар кабул итүне тәмамлау датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый;

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 2.7 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яисә) битләре күрсәткечләре;

әлеге Нигезләмәнең 2.3 пункты һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр;

әлеге Тәртипнең 3.2 пункты нигезендә сайлап алу критерийлары;

тәкъдимәр (заявкалар) бирү тәртибе һәм бу Тәртипнең 3.3 пункты нигезендә тәкъдимәр (заявкалар) формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире алу тәртибе, тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире кайтару (шул исәптән тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире кайтару өчен нигезләр билгеләнә торган) тәртибе, тәкъдимнәргә (заявкаларга) үзгәрешләр кертү тәртибе;

әлеге Тәртипнең 3.4 пункты нигезендә (тәкъдимнәрне) заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

эшләп бетерү өчен тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире кайтару тәртибе;

тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире кагу тәртибе, шулай ук әлеге Тәртипнең 3.4 пунктының 3.4.8 пунктчасы нигезендә аларны кире кагу нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, әлеге Тәртипнең 2.6 пункты нигезендә субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуның җиңүчесенә (җиңүчеләргә) бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) килешү имзаларга тиешле вакыт;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (читләшкән) дип тану шартын;

сайлап алу йомгаклары беркетмәсен (сайлап алуны уздыру йомгаклары турындагы документны) бердәм порталда урнаштыру сроклары, алар сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннең иртәгесеннән соңгы 14 календарь көннән дә соң була алмый.

3.2. Сайлап алуда катнашучылар түбәндәге сайлап алу критерийларына (тәкъдим (заявка) бирелгән датага карата) туры килергә тиеш:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру һәм сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштыру датасына кимендә бер ел Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

чараларны оештыру һәм уздыру эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

3.3. Сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тәкъдимнәр (заявкалар) формалаштыру һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе.

3.3.1. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән срокларда тәкъдимне (заявканы) «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзи һәм бирә һәм «Электрон бюджет» системасына документларның электрон

күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыра, аларны бирү сайлап алу үткәрү турында игъланда каралган.

«Электрон бюджет» системасында сайлауда катнашучы тарафыннан формалаштырылган тәкъдим (заявка) сайлап алуда катнашучы яисә ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан (тәкъдим) заявка бирү датасы булып, (тәкъдимгә) заявкага «Электрон бюджет» системасында теркәлү номеры бирелеп, аңа сайлап алуда катнашучы тарафыннан имза салынган көн санала.

3.3.2. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашу өчен түбәндәге документларны үз эченә алган (тәкъдимне) заявканы «Электрон бюджет» системасында урнаштыра:

сайлап алуда катнашучы турында мәгълүматны үз эченә алган субсидия бирү хакында әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге рәвеш буенча аның тарафыннан тәкъдим ителә торган гариза;

юридик зат - сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең (ул вәкаләтләр биргән затның) вәкаләтләрен раслый торган документларның яисә шәхесне таныклый торган документның (индивидуаль эшкуарлар өчен) күчермәләре;

тәкъдим (заявка) бирү датасына бирелгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

сайлап алуда катнашучының (тәкъдим) заявка биргән айга кадәрге айның 1 числосына бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән югарырак булмау (мондый документны сайлап алуда катнашучы тарафыннан күрсәтелмәгән очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат, сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмауны раслый торган салым орган белешмәсе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган тәкъдим (гариза), сайлап алу белән бәйле башка мәгълүматны бастыруга (урнаштыруга) ризалык;

әлеге Тәртипнең 2.6 пункты нигезендә билгеләнгән, сайлап алуда катнашучы җитәкчесе һәм баш хисапчысы (бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи зат) тарафыннан имзаланган субсидия күләмен исәпләү (ирекле рәвештә);

чараны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле гамәлдәге чыгымнарны раслый торган документларның күчермәләре: шартнамәләр, түләү йөкләмәләре, наклад, счетлар, фактур, башкарылган эшләр актларының;

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында каралган критерийларга туры килүен раслый торган ирекле рәвештә төзелгән һәм сайлап алуда катнашучы җитәкчесе үзе кул куйган яисә электрон цифрлы имза ярдәмендә имзаланган белешмә;

төзелгән килешү нигезендә һәр позицияне күрсәтеп, күрсәтелгән хезмәтләр, башкарылган чаралар турында фото-, видеоматериаллар кушымтасы белән фотохисап яхшы укыла торган рөхсәт белән (һәр позициянең берәр нөсхә фотосурәт белән).

3.3.3. Тәкъдимгә (заявкага) кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә якланган булырга тиеш түгел.

Тәкъдимгә (заявкага) кертелгән фото- һәм видеоматериалларда югары сыйфатлы ачык һәм контрастлы сурәт булырга тиеш.

3.3.4. Тәкъдимдә (заявкада) булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә сайлап алуда катнашучы җаваплы була.

3.3.5. Сайлап алуда катнашучы тәкъдимне (заявканы) сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, тәкъдимнәр (заявкалар) бирү өчен билгеләнгән срок эчендә тәкъдимне (заявканы) кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта тәкъдим (заявка), “Электрон бюджет” системасында теркәлү номеры бирелеп, чират тәртибендә кергән көндә теркәүгә алына.

3.3.6. Сайлап алуда катнашучы тәкъдимне (заявканы) үзгәртергә хокуклы:

сайлап алуда катнашучы электрон формада формалаштырылган тәкъдимнәрне (заявкаларны) кире алу турында хәбәрнамәдән һәм алга таба яңа тәкъдим (заявка) төзелгәннән соң тәкъдимнәрне (заявкаларны) кабул итү срогы тәмамланган көнгә кадәр;

тәкъдимне (заявканы) карау этабында тәкъдимнәрне (заявкаларны) карау буенча комиссия (алга таба - комиссия) карары буенча гаризаны кире кайтару турында.

Тәкъдимгә (заявкага) үзгәрешләр кертү яисә тәкъдимне (заявканы) кире алудан соң тәкъдимне (заявканы) кабат бирү әлеге Тәртипнең 3.3 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучының тәкъдимен (заявкасын) бирүнең шундый ук тәртибендә сайлап алуда катнашучы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.3.7. Төгәлләштерелгән тәкъдим (заявка) сайлауда катнашучы тарафыннан тәкъдим (заявка) эшләп бетерүгә кире кайтарылганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча кабат җибәрелә.

Комиссиянең тәкъдимнәрне (заявкаларны) сайлап алу катнашучыларына эшләп бетерүгә кире кайтару турында карары тәкъдимнәрен (заявкаларын) караганда аларны эшләп бетерүгә кире кайтару өчен нигезләр ачыкланган сайлап алуның барлык катнашучыларына карата тигез дәрәҗәдә кабул ителә, шулай ук «Электрон бюджет» системасын кулланып сайлап алуда катнашучыларга ул кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә, тәкъдимне (заявканы) кире кайтару өчен нигезләр, шулай ук эшләп бетерүгә мохтаҗ тәкъдимнәр (заявкалар) нигезләмәләрен күрсәтеп, җиткерелә.

3.3.8. Сайлап алуда теләсә кайсы катнашучы бердәм порталда сайлау үткәрү турында игълан урнаштырылган көннән башлап тәкъдимнәр (заявкалар) бирү тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча вәкаләтле органга «Электрон бюджет» системасында тиешле таләпне формалаштыру юлы белән сайлап алу үткәрелү турында игълан нигезләмәләрен аңлату турында кимендә өч сорату җибәрергә хокуклы.

3.3.9. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 3.3 пунктының 3.3.8 пунктчасында күрсәтелгән соратуга җавап итеп, «Электрон бюджет» системасында аңлатмалар соратып алу көненнән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча, әмма тәкъдимнәр (заявкалар) бирү тәмамланган көнгә кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле аңлатманы «Электрон бюджет» системасында булдыру юлы белән сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуны уздыру турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату күрсәтелгән белдерүдә булган мәгълүматның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

